**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БЕДЕНЬГИНСКОГО СЕЛЬКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422385 с. Татарская Беденьга, ул. Вахитова, 41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР БИДЕНГЕ АВЫЛЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422385 Татар бидәңге авылы, Вахитов урамы, 41

тел. (84373) 5-05-40, 5-05-40, факс 5-05-40, e-mail: tat.beden@mail.ru
ИНН/КПП 1638005347/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**24.04. 2025** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлеге Башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында»01.12.2022 елның 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Җир кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында " 26.12.2024 ел, № 485-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлеге Башкарма комитетының 01.12.2022 no 7 карары белән расланган Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм алардан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.3. Автомобиль юлының юл буе полосалары - беренче, икенче яисә өченче категорияле автомобиль юлына бүленгән полосага ике яктан да якын урнашкан һәм чикләрендә юл хәрәкәте иминлеге таләпләрен, шулай ук автомобиль юлын реконструкцияләүнең, капиталь ремонтлауның, ремонтлауның, карап тотуның нормаль шартларын, аның сакланышын исәпкә алып, җир кишәрлекләреннән (җир кишәрлекләренең өлешләреннән) файдалануның махсус режимы билгеләнә торган территорияләр автомобиль юлын үстерү перспективалары;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **Г.З.Галиева**